КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 март г.Казань № 239

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2022 елларга «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче карары белән расланган 2018 – 2022 елларга «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2022 елларга «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 4 июль, 549 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2018 – 2022 елларга «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме</td>
<td>Программаны финанслауның гомуми күләме 10 847 860,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барлыгы*</th><th colspan="2">Шул исәптән *</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджет акчасы</th><th>җәлеп ителергә планлаштырылган федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2018</td><td>3 574 608,9</td><td>2 014 500,0</td><td>1 560 108,9</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>3 273 251,7</td><td>2 000 000,0</td><td>1 273 251,7</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>2 000 000,0</td><td>2 000 000,0</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>2 000 000,0</td><td>2 000 000,0</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>*</td><td>*</td><td>*</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1 084 7860,6</td><td>8 014 500,0</td><td>2 833 360,6</td></tr>
</table>
*Искәрмә: Чараларны финанслау күләмнәре тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары арасында субсидияләр бүлү нәтиҗәләре буенча ел саен тәгаенләнергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

Программаның 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2019 ел Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 ел, 7 май, 204 нче Указын үтәү йөзеннән расланган илкүләм проектлар өчен старт елы булды.

Программа чараларын тормышка ашыру «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектының «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты кысаларында дәвам итәчәк, анда, моннан тыш, кече шәһәрләрдә һәм тарихый җирлекләрдә уңайлы шәһәр мохитен булдыруның иң яхшы проектлары буенча бөтенроссия конкурсында җиңүчеләр проектларын федераль бюджет акчасы исәбеннән тормышка ашыру карала.»;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 10 847 860,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 8 014 500,0 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 2 833 360,6 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Акча барлыгы* | Шул исәптән * | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы |
| 2018 | 3 574 608,9 | 2 014 500,0 | 1 560 108,9 |
| 2019 | 3 273 251,7 | 2 000 000,0 | 1 273 251,7 |
| 2020 | 2 000 000,0 | 2 000 000,0 | * |
| 2021 | 2 000 000,0 | 2 000 000,0 | * |
| 2022 | * | * | * |
| Барлыгы | 10 847 860,6 | 8 014 500,0 | 2 833 360,6 |

*Чараларны финанслау күләмнәре тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары арасында субсидияләр бүлү нәтиҗәләре буенча ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

4 бүлекнең алтынчы абзацында «2018 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Программага теркәлгән 2 нче кушымтада:

3 нче графада:

5 нче юлда «Гагарин урамы» сүзләрен «Тукай урамы» сүзләренә алыштырырга»;

14 нче юлда «Әнәк авылы, Нур Баян урамы» сүзләрен «Әнәк авылы, Нур Баян урамы, Ленин урамы» сүзләренә алыштырырга;

19 нчы юлда «Гагарин урамы» сүзләрен «Куйбышев сусаклагычы» сүзләренә алыштырырга;

33 нче юлда «Апас шәһәр тибындагы поселогы. Табар елгасы яр буе» сүзләрен «Табар Черкене авыл җирлеге. Табар елгасы яр буе, 2-нче чират» сүзләренә алыштырырга;

61 нче юлда «Р.Люксембург урамы» сүзләрен «Космовский урамы» сүзләренә алыштырырга;

65 нче юлда «Приволжская урамы» сүзләрен «Набережная урамы» сүзләренә алыштырырга;

66 нчы юлда «, Кольцевая урамы» сүзләрен төшереп калдырырга;

70 нче юлда «Аптечная урамы» сүзләрен «Центральная урамы» сүзләренә алыштырырга;

78 нче юлда «Зәй урамы» сүзләрен «Кызыл мәйдан урамы» сүзләренә алыштырырга;

85 нче юлда «Ленин урамы» сүзләрен «Гагарин урамы» сүзләренә алыштырырга;

95 нче юлда «Заовражный Каратай поселогы» сүзләрен «Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» сүзләренә алыштырырга;

98 нче юлда «Ленин урамы» сүзләрен «Комсомол урамы» сүзләренә алыштырырга;

112 нче юлда «Тукай урамы» сүзләрен «Добролюбов урамы» сүзләренә алыштырырга;

130 нчы юлда «Г.Тукай урамы» сүзләрен «К.Маркс урамы» сүзләренә алыштырырга;

137 нче юлда «Тукай урамы» сүзләрен «Пушкин урамы» сүзләренә алыштырырга;

165 нче юлда «Пионерлар урамы» сүзләрен «Яшьләр урамы» сүзләренә алыштырырга;

191 нче юлда «, Гоголь урамы» сүзләрен төшереп калдырырга;

Программага теркәлгән 5 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин